**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.10.2024 № 1233

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә халыкка мунча хезмәтләре күрсәтүне гамәлгә ашыручы юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - хезмәтләр җитештерүчеләргә чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1.Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. 1нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә халыкка мунча хезмәтләре күрсәтүне гамәлгә ашыручы юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга - хезмәтләр җитештерүчеләргә чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе;

1.2. 2нче кушымта нигезендә Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны, физик затларны - хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләрне сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия;

1.3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә халыкка мунча хезмәтләре күрсәтүне гамәлгә ашыручы чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү буенча эшче төркемгә 3нче кушымта нигезендә;

1.4. 4нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә халыкка мунча хезмәтләре күрсәтүне гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, физик затлар - хезмәтләр җитештерүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифлар.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар секторы әлеге карарда билгеләнгән функцияләрне башкаручы вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән дип билгеләргә.

3. Бюджет турындагы карар яисә бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карар нигезендә бирелергә тиешле субсидияләр турындагы мәгълүмат, катнашучыны сайлап алуны үткәрү турындагы мәгълүмат (әгәр субсидия сайлап алу

нәтиҗәсе буенча бирелсә) «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының мәгълүмат-телекоммуникация системасындагы бердәм порталында «Интернет»челтәрендә урнаштырыла дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәрендә халыкка мунча хезмәтләре күрсәтүне гамәлгә ашыручы юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга-хезмәтләр җитештерүчеләргә чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында" 2023 елның 23 мартындагы 278 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5**.** Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин